СОВЕТ
УРНЯКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Лесная, д. 44А, п.Урняк,
Арский муниципальный район, 422019

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ҮРНӘК
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Урман урамы, 44А йорты, Үрнәк авылы,
Арча муниципаль районы, 422019

Тел. (84366)51-4-93, факс (84366)51-4-93. E-mail: Urn.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы**
**КАРАРЫ**

**27 октябрь 2025 ел** **№14**

**Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Алга-Көек авылында граждан-нарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

"Ачык хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми прин-циплары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон-ның 45, 69 статьялары, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 ел-ның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Арча муниципаль районының Үрнәк авыл җирлеге Уставының 25 статьясы, Арча муни-ци-паль районының Үрнәк авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы карар чыгар-ды:

1. Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Алга-Көек авылында Алга-Көек авылы, Татарстан урамы, 12 нче йорт янында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2025 елның 18 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта халык җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Алга-Көек авылында Алга-Көек авылы, Комсомол урамы, 23 нче йорт янында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2025 елның 18 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта халык җыенының икенче этабын билгеләргә.

3.Торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлүне территория буенча башкарыр-га:

1 нче этап: Татарстан урамында яшәүчеләр;
2 нче этап: Комсомол, Пионер урамнарында яшәүчеләр.

4. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез 2026 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирле-ге Алга-Көек авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган ак-чаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына ризамы:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (кышкы чорда җирле әһәмиятле юлларны кардан чистарту)

- урамнарны яктырту җайланмасы (урамнарны дежур яктыртуны сатып алу һәм урнаштыру; яктырткычлар сатып алу)

-торак пункт территориясен төзекләндерү (Пионер урамы башында шлагбаум урнаштыру)?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

"ӘЙЕ" "КАРШЫ"

5. Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Алга-Көек авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Үрнәк авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасының Рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга һәм халык күплəп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендына түбəндəге адрес буенча урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Арча районы, Алга-Көек авылы, Татарстан урамы, 19 нчы йорт.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Үрнәк авыл җирлеге башлыгы В.Р.Габделхаков